Март • 2021 ел • № 3 (39)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

# Безнең чемпионнар

Казан шәһәренең «Ак Барс» көрәш сараенда Россия беренчелегенә билбау көрәше бәйгесе үткәрелде. Анда Россия Федерациясенең 20 регионыннан 300гә якын көрәшче катнашты.

Үзебезнең гимназиядә белем алучы 7а сыйныфы укучысы Фазыл Сибгатуллин, үз авырлык үлчәвендә батыр калып, Россия чемпионы исемен яулады.

Әлеге ярышта катнашкан 7а сыйныфы укучысы Булат Вәлиев шулай ук үз үлчәвендә Татарстан буенча беренче урынны һәм Россия буенча өченче урынны яулады.

Батырларның уңышы – шәхси тырышлык һәм оста тренер хезмәте.Утыз елга якын тренерлык тәҗрибәсе булган Шәмсевәлиев Илгиз Вәгыйзь улы дөнья чемпионнарын тәрбияләүче остазларның берсе. Билбау көрәше буенча дүрт тапкыр дөнья чемпионы – Вадим Василевны, өч тапкыр дөнья чемпионы – Ранис Гыйләҗетдиновны, республика сабантуйлары батырларын тәрбияләгән тренер ул Илгиз Вәгыйзь улы. Аның йөзендә һәрвакыт тыйнак елмаю һәм хәрәкәтләрендә җитезлек. Остазның кул астында шөгыльләнүчеләр дә үзе кебек тәрбияле, тыйнаклар.

Әлеге батырларны гимназиядә тантаналы рәвештә зурлап котладылар. Гимназия директоры Гарифуллин Айдар Хәкимҗан улы, үзе дә әлеге спорт төрен үз иткәнгә, батырларның уңышларына эчкерсез шатлануын белдерде. Шәмсевәлиев Илгиз Вәгыйзь улы, үз чиратында, гимназия директорына көрәш белән шөгыльләнү өчен бөтен шартлар тудыруы өчен рәхмәтен җиткерде. Ә батырларны котлаганда, ул: «Бу батырлар командасын мин беренче елда ук альфа-команда дип атадым, чөнки бик сәләтле малайлар төркеме ул», – диде.

Батырларның үзләренә килгәндә, аларның уңышларында ата-аналарының өлешләре бик зур. Фазыл Сибгатуллинның тагын ике игезәк туганы Фаяз белән Хәсән дә көрәшәләр. Алар укуда да бик тырышлар. Булат та укуга җитди карый. Чын спортсмен һәр яктан үрнәк булырга тиеш.

Егетләргә бүләк итеп матур түбәтәйләр кигерттеләр, ә әниләренә тапшырыр өчен, кәрзин белән чәчәкләр бирделәр. Билбау көрәше батырларының фотосурәтләре реклама щитларына эленәчәк. Ул фотосурәтләрне күргәч, без тагын бер кат үзебезнең гимназия батырлары белән горурланырбыз әле.








# #винеркрутой

«Көмеш кыңгырау» хезмәткәрләре миңа куанычлы бүләк ясадылар: журналист сыйфатында Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы дәүләт драма театрының яшь артисты Винер Ринат улы Фәйзуллиннан интервью алырга мөмкинлек тудырдылар. Әлбәттә, мин бераз дулкынландым. Театр бинасына кергәч, күңелемне тынычлык хисе биләде, чөнки булачак әңгәмәдәшем Винер абый мине күптәнге танышы кебек каршылады һәм аның эчкерсезлеге минем уйларымны тәртипкә салды.

**– Хәерле көн, Винер абый. Сезнең турыда Интернет челтәрендә бик аз, әмма кызыклы гына мәгълүмат табарга мөмкин. Сез тумышыгыз белән Ырынбур ягыннан, сезгә 20 яшь, сәхнәгә килү тарихыгыз да кызык кына килеп чыккан. Әйдәгез, шул турыда иркенләп сөйләгез әле.**

– Мин элек чаңгы белән шөгыльләнә идем: Әсәкәй районы чемпионы булдым, Ырынбур өлкәсендә сигезенче урында тора идем. Соңыннан спортны сәхнә җиңде. Ул вакытны әнием музыка укытучысы булып эшкә урнашты. Ул мине районның җыр бәйгесенә барырга күндерде. Мин анда «Тал бишек» җырын башкардым. Үзем сәхнәдә торам, чалбарымны уам, микрофоны да өзек-өзек кенә эшли, кемдер, кулымнан микрофонны алып, аны алыштырып тора, ә мин, текстны онытмас өчен, туктамыйча җырымны дәвам итәм, микрофон артыннан тартылам-сузылам. Өйгә кайткач, мин әнигә бүтән гомеремдә дә сәхнәгә басмаячагым турында әйттем.

Икенче бәйге вакыты килеп җитте, әни тагы үгетләргә тотынды. Мин ул вакытта казылык (колбаса) ярата идем. Шулчак әни өченче урын алсаң – бер, икенче урын өчен – ике, ә беренче урын өчен өч казылык алып бирермен диде. Анда мин өченче урынны яуладым. Әни барыбер икене алып бирде. Шуннан соң инде миндә сәхнә җене кузгалды.

**– Ни өчен сез Казан театр училищесына укырга керергә булдыгыз?**

– Дөресен генә әйткәндә, тугызынчы классны бетергәндә, кая керергә дә белмәдем. Җырчы буласым килде. Казан театры училищесы турында ишеттем. Мин укырга кердем, хәзер җырчы булып чыгам дип уйлыйм бит инде. Дәресләр башланды, укытучылар бездән әллә нинди этюдлар сорыйлар, без аптырадык, җырларга өйрәтмиләр. Вокал үзе икенче курстан гына башланды. Беренче курста ансамбльдә шөгыльләндек. Аннан соң, беренче курсны тәмамлаганда, мин театрга гашыйк булдым һәм театрда эшлисем килде, әлбәттә, эшләдем.

**– Яр Чаллы драма театрына килү тарихыгыз ничек булды?**

– Безнең ике мастерыбыз булды, берсе – Закиров Зөлфәт Хакимович – ул Тинчурин театрының актёры, икенчесе – Гарипова Резидә Ирековна – Тинчурин театрының режиссёры. Резидә апа безнең белән Уильям Шекспирның «Цембелин» дигән спектаклен куйды, анда мин королеваның улын уйнадым, ә Олег Кинҗәгулов безнең уйнаганны карарга килде. Ул киткәндә: «Курстан миңа өч кеше кирәк булачак», – дип әйткән. Мастер керде дә безгә: «Кемнәр икәннәрен әйтмим әле, борыныгызны күккә чөячәксез, укымый башларсыз», – диде. Без бу вакыйганы бөтенләй онытттык, карантин башланды. Ул вакытта мин авылга кайтып киттем, юллар вакытлыча ябылды. Чикләүләр бераз кимегәч, Казанга эшкә урнашырга киттем. Уку юк. Төзелештә эшлим, фундаментлар салабыз. Беркөнне, өйгә кайтып барганда, телефон «тавыш биреп куйды»: мине бер группага кертеп куйганнар, анда минем тагын курсташым Физәлия дә бар. ут Фирдүс минем икенче курсташым, ул да берни белми. Нинди группа бу? Кем безне монда керткән? Соңыннан Физәлиягә шалтыратырга булдык, бу группага безне Олег Кинҗәгулов керткән булып чыкты, без инде барысын аңладык, шулай сөйләшеп, беркөнне очрашырга булдык. Олег Кинҗәгулов Чаллыда эшләргә тәкъдим итте, мин ризалаштым.

Әмма мин монда эшләргә килгәч, озакка калмам дип уйлаган идем: бер-ике ай гына эшләп алырмын да киредән Казанга кайтырмын. Аннары миңа «ШәҺәр. Нокта. Брежнев» спектаклендә төп рольне бирделәр, шуннан мин Чаллыга гашыйк булдым, хәзер Казанга киредән кайтасы да килми .

**– Чаллы шәһәре сезгә нәрсә белән ошый? Шул шәһәр яшүсмерен уйнау сезгә авыр булдымы?**

– Бу спектакльдә бераз уйнарга кыенрак булды, әле үзем дә бит белеп бетермим, сиксән өченче ел балалары нинди ул? Бу вакытта мин тумаган да әле, Чаллы шәһәре бар икәнен дә белмим. Нинди авырлыклар булса да, мин үземнең ролемне бик нык яратып башкарам.

**– Сезнең театр дөньясында кумирыгыз бармы?**

– Әйе, бар. Ләкин ул хәзер сирәк күренә. Аның исеме Том Харди. Ниндидер фильмда Том Хардиның уйнаганын белсәм, шунда ук карыйм.

**– Артист өчен иң мөһим сыйфат нинди дип уйлыйсыз?**

– Артист кеше, сәхнәдә уйнаганда ролենә бирелеп, тамашачыны ышандырырлык итеп уйнау, уйларыңны чәчмәү.

**– Актер-музыкант буларак, иң яратып башкарган ролегез кайсысы?**

– Мин бар рольләремне дә яратып уйнадым, һәм һаман аларны яратам, әмма иң нык миңа ошаган роль ул шул Артур роле .

**– Сез буш вакытыгызда ни белән шөгыльләнәсез?**

– Буш вакытымда мин җырлар язам. Күбрәк рэп. Әле хәзер дә җыр язам,ул әниемә багышланган була. Әле җырның кушымтасын яздым, эшләп бетерәсем бар.

**– Киләчәктә нинди рольләрдә уйныйсыгыз килә?**

– Киләчәктә, минем бер мистик яки бер куркыныч геройны уйныйсым килә. Тамашачы шул геройдан курыксын да, кызыгып та аңа карап торсын иде.

**– Сез буш вакытыгызда кызыклы видео язмалар төшерергә яратасыз икән, һәм аның астында #ВИНЕРКРУТОЙ дип язып калдырасыз. Бу нәрсә аңлата?**

– Әйе, видеолар төшерергә бик яратам. Бу язма бернәрсәне дә аңлатмый инде. Һәр артистның үзенең фишкалары бар бит, мин дә шулай #ВИНЕР КРУТОЙ дип язарга булдым. Мин Егор Кридның бер җырын тыңлаган идем, анда да шулай, Игорь крутой дип җырлыйлар иде, миңа бу нык ошады да, үзем дә шулай язарга булдым.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Винер абый. Сезгә киләчәктә яңа үрләр, иҗади ачышлар, тамашачы мәхәббәте телибез.**

Менә нинди икән Ырынбур егете Винер абый! Бу матур әңгәмә аның да күңелендә калыр дип уйлыйм. «Тормыш – театр, ә без анда артистлар» дигән Шекспир сүзләрен исемә төшереп, мин дә дәрес әзерләргә утырдым, шулай да, бер генә көнгә журналист булу бәхетен бүләк иткән «Көмеш кыңгырау», рәхмәт сиңа!

**Алия НУРИСЛАМОВА**

# Ак калфаклы татар кызы



Гимназиянең 11 А сыйныф укучысы Биктимирова Нәзилә Рөстәм кызы «Ак калфаклы татар кызы» бәйгесендә катнашты, җиңүче дипломы белән бүләкләнде. Нәзиләгә әлеге бәйгедә үзе белән таныштырырга, бию осталыгын күрсәтергә, жюри сынавын узарга, токмач кисәргә, дисбе җыярга туры килде. Нәзилә сынатмады, һәр эшен пөхтә итеп башкарды, акыллы җаваплар бирде, чын татар кызы икәнен күрсәтте. Әйдәгез, Нәзиләнең «Кем соң ул татар кызы? Аңа нинди сыйфатлар хас?» дигән сорауга җавап рәвешендә биргән фәлсәфи карашы белән танышыйк.

«Минемчә, чын татар кызы, иң беренче чиратта, ул үз ана телен камил белергә тиеш. Ана теленә мәхәббәт кечкенәдән бишек җырлары, әкиятләр, татар көйләре аша сеңә. Татар кызлары тәрбияле, укымышлы, иманлы, шул ук вакытта заман таләпләренә дә яраклаша белергә тиеш. Ә шулай да аларга хас сыйфатлар, минемчә тыйнаклык һәм әдәплелек.

«Ак калфак» премиясенә дәгъва иткән кызлар, һичшиксез, әлеге сыйфатларга ия булырга тиешләр. Миңа да әлеге сыйфатлар хас, дип уйлыйм. Ә ни өчен нәкъ менә мин премиягә лаек икәнен хәзер ачыклыйм.

Мин – Биктимирова Нәзилә, Чулман буенда урнашкан Яр Чаллы шәһәреннән. Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиядә белем алам. Гаиләмдә саф татар телендә аралашам. Татар теле һәм татар әдәбиятыннан олимпиадаларда катнашу минем туган телемә булган кызыксынуымны үстерде, шәхес буларак яңа сыйфатлар белән баетты. Олимпиадалардан тыш мин фәнни конференцияләрдә, шигырь укучылар бәйгеләрендә катнашып, призлы урыннар алдым, «Ел укучысы-2015» бәйгесендә җиңүче булдым. Һәр җиңүем тагын да күбрәк укырга, тагын да татар халкын, аның культурасын күбрәк өйрәнергә этәргеч бирде.

Мәктәп тормышында да мин бик актив катнашам. Күп кенә бәйрәмнәрне, бәйгеләр оештырам, конферанс буларак алып барам. Кичәләрне оештырганда, минем иң мөһим таләбемнең берсе – аларны татар телендә алып бару, чөнки минемчә, туган телгә мәхәббәт мәктәптә тәрбияләнергә тиеш. Моның өчен укучыларга туган телне матур итеп уен формасында өйрәтүдән башларга кирәк. Бу эшне эзлекле төстә алып бару безнең телебезгә игътибарны арттырыр иде. Яшәр һәм эшләр өчен кирәк булмаган телне бик сирәкләр генә өйрәнә.

2020 елда язмыш мине «Сәләт» Балалар һәм Яшьләр оешамасы белән таныштырды. Сәләт дөньясына мин беренче караштан ук гашыйк булдым. Әлеге оешмада мин үземдә күп дуслар, фикердәшләр таптым.

Мин яхшы билгеләргә генә укыйм, имтиханнарга әзерләнәм. Буш вакытым юк диярлек, ләкин мөмкинлек булганда, музыка тыңларга, театрга йөрергә яратам. Һәр елны Казанда уздырылучы «Мин татарча сөйләшәм» акциясе, «TatCultFest» чараларында теләп катнашам.

Күп кенә фестивальләрдә, форумнарда, бәйгеләрдә катнашу сәбәпле, төрле яшьләр белән аралашырга туры килә. Шулвакыт мин яшьтәшләремнең күзләрендә үз милләтем белән горурлану чаткыларын күрәм, ирексездән, үз эчемнән уйлап куям: «Бу күзләр алдамый, татарның киләчәге бар, һәм ул киләчәк – безнең кулларда!»

Телне саклап үстерү – дәүләт күләмендәге, бөтен дөнья масштабындагы сәяси эш. Чөнки һәрбер тел ул – аз санлы кешеләрнеке булса да, күп санлы милләтнеке булса да – халык иҗат иткән чиксез кыйммәтле хәзинә. Тел яшәсә, халык та яши, тел бетсә, халык та бетә».

**Нәзилә БИКТИМИРОВА**



# Суфиян абыйга ачык хат

Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен укып чыккач, мин Акъәбинең иң олы улына Суфиянга шундый хат язарга булдым:

«Исәнмесез, Суфиян абый. Бу хат аша мин сезгә ялгыш адымыгыз турында фикерләремне җиткерәсем килә. Сез үз әниегезне соңгы тормыш көннәрендә хастаханәгә илтеп куюыгызны дөрес итеп уйлыйсызмы? Ул бит сезне бу дөньяга тудырган, сезне үстергән, сезне бөтен җаны-тәне белән яраткан, укыткан, кеше иткән. Сез, Суфиян абый, тормышта үз урыныгызны тапкач, әни янына кайтырга вакыт та таба алмагансыз. Сез балаларыгызны, хатыныгызны үзегезне хөрмәт итәргә өйрәтмәгәнсез. Әни кеше бала турында көн саен уйлый. Ул бит, Суфиян абый, сезнең аның янына кайтыгуызны һәр көн көткән. Күпме балалар үстереп, картаймыш көнендә ялгыз калган. Авыр чакта күрше кызы булышкан булышуын, ә сез, тормыш куып, үз әниегез янына кайтырга вакыт таба алмагансыз. Ул сезгә рәнҗедеме икән, әллә инде сезне акларга теләдеме икән? Сез аны шәһәргә алып киткәч тә, аның соңгы теләкләренә колак салырга вакыт тапмыйсыз. Сез, Суфиян абый, аның олы улы була торып, ничек үз әниегезне соңгы көннәрендә хастаханәгә җибәрергә мөмкинлек бирдегез? Ул бит сезнең иң якын кешегез – әниегез! Ә аның сандыгындагы камчыга гаилә мирасы дип үрелдегез. Шушы хәлләрдән соң нинди күңел белән яшәрсез икән? Сезнең картлык көнегез ничек булыр? Уйлагыз әле...

Сау булыгыз!»

*Сәлам белән*
**Азалия ӘХМӘТҖАНОВА,**
*7а сыйныфы*

# Ничек яхшы булырга?

«Яхшы булу»ны һәрбер кеше үзенчә аңлый. Минемчә, «яхшы кеше» – ул эчкерсез, кешелекле һәм югары әхлакый сыйфатларга ия кеше. Минем якыннарым арасында андый кешеләр күп. Минем әти-әниләрем, әби-бабайларым, укытучыларым минем өчен үрнәк. Алар мине алдашмаска, икейөзле булмаска, тугры булырга өйрәтәләр. Кешеләргә авыр минутларда ярдәм итү мөһим булу турында сөйлиләр. Мин аларның киңәшләрен үтәргә, бары тик яхшы адымнар гына ясарга тырышам. Берәр адым ясаганчы, җентекләп уйлыйм. Минем кылган гамәлләрем горурланырлык һәм йөзгә кызыллык китермәстәй булырга тиеш.

Яхшылык эшләү, ярдәм итү, эчкерсез булу – зур бәхет. Чөнки кешеләргә яхшылык эшләгәннән соң, мин үземне бәхетле тоям.

**Нәзилә ӘХМӘТҖАНОВА,**
*3а сыйныфы*

# «Бишле»...

Әллә бишле алгангамы
Көн матуррак күренә.
Миңа карап кояш көлә
Шатлык сыймый эчемә!
Җитез генә өйгә кайтам:
Гөлләремә су сибәм,
Савыт-сабаларны юып
Өебезне ялт итәм!
Тиз генә өй эшен эшлим
Көндәлекне тутырам.
Төсле матур каләмнәрне
Пеналга очлап куям...
...Бермәлне, уянып китсәм...
Кичке биш булган икән...
Шаккатып ишек төбендә
Әнием тора икән!..
Савыт-саба юылмаган,
Гөлләр суга сусаган...
Җитмәсә көндәлегемә –
Икеле менеп утырган!
Бер кызарам, бер агарам
Әнигә торам карап.
Күрсә минем «шәп» билгене
Була эшләрем харап!

**Алинә ҖИҺАНШИНА,**
*3б сыйныфы*




Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА